РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

28.08. 2020 ел №294

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының 2017 елның 13 декабрендәге 130 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеген раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14 статьясы, 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 ст. «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль милкенә ия булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү тәртибе турындагы нигезләмә», Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2010 елның 10 сентябрендәге 194 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының 2017 елның 13 декабрендәге 130 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль милек

исемлеген раслау турында» карарына (район Советының 2018 елның 13 декабрендәге 199 номерлы, 2019 елның 13 декабрендәге 260 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

1.1. Әлеге карарга кушымта нигезендә күчемсез милек объектларын исемлектән төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасарына һәм район Советының икътисади сәясәт һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы, Совет рәисе Ф.М. Дәүләтшин

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Советының 2020 елның
28 августындагы 294 номерлы
карары белән

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2017 елның 13 декабрендәге 130 номерлы карары белән (район Советының 2018 елның 13 декабрендәге 199 номерлы, 2019 елның 13 декабрендәге 260 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән өченче затларның хокукларыннан ирекле Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендәге муниципаль милекнең исемлеге

| № п/п | Милекнең исеме | Милекнең урнашу урыны | Мәйданы (кв.м.) |
|---|---|---|---|
| 1 | Бина | Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Чирмешән авылы, Беренче Май ур., 27 йорт | 20,7 |
| 2 | ФАП бинасы | Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Казанка авылы, Школьная ур., 35 йорт | 76,9 |
| 3 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Түбән Кәминкә авыл җирлеге Кадастр номеры: 16:41:180302:564 | 86799 |
| 4 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Кармыш авыл җирлеге Кадастр номеры: 16:41:030303:16 | 100000,0 |